**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ДЕРЖАВИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422620,Татарстан, с. Державино,
ул. Заббарова, д.39
тел: 3-45-20

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ДЕРЖАВИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422620 Державино авылы,
Заббаров урамы, 39 нчы йорт,
тел: 3-45-20

**2020елның 5 августы** **70 номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Державино авыл җирлеге Советына депутатлыкка кандидатларның, Державино авыл җирлегенең 1767 номерлы сайлау участогы территориясендә басма агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар бүлеп бирү турында.**

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Державино авыл җирлеге Советына депутатлыкка кандидатлар өчен 1767 номерлы сайлау участогы территориясендә басма агитация материаллары урнаштыру өчен махсус урыннар бүлеп бирү турында Татарстан Республикасы Лаеш районы территориаль сайлау комиссиясе тәкъдимен карап тикшергәннән соң, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 54 статьясындагы 7 пунктына, Татарстан Республикасы Сайлау Кодексының 64 статьясындагы 8 пунктына таянып, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Державиноо авыл җирлеге Советына депутатлыкка кандидатларның басма агитация материалларын 1767 номерлы сайлау участогы территориясендә урнаштыру урыны итеп Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Державино авылы, Җаббаров ур., 39й. адресы буенча урнашкан мәгълүмати стендны билгеләргә.

2. Карарны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының территория сайлау комиссиясенә җибәрергә.

3 .Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Державино авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе** **И.И.Камалиева**